Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советы Карары

14 май 2021 ел № 25

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 декаберендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Территорияләрне комплексly үстерүне тәэмин итү максатларында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 30.12.2020 ел, № 494-ФЗ Федераль закон нигезендә», Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 83 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советының
2021 елның 14 маендагы 25 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 декаберендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Өҗем авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 83 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**12 статьяның 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:**

**«** җирлекнең генераль планына, шәһәр округының Генераль планына үзгәрешләр әзерләү очракларыннан тыш, территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителү белән бәйле җәмәгать тыңлаулары яисә гавами тыңлаулар, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин».